**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧИРПОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422615 с. Чирпы,
ул. Заводская, д.22
тел: 8 (84378) 2-91-45
E-mail: Chirp.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРПЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422615 Чирпы авылы,
Завод урамы, 22 йорт,
тел: 8 (84378) 2-91-45
E-mail: Chirp.La@tatar.ru

---

**2023 елның 18 декабре** **18 номер**

# КАРАР

## Чирпы авыл җирлеге территориясендә пиротехника эшләнмәләрен куллану урыннары турында

Яңа ел бәйрәм чараларын үткәрү вакытында, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге, физик һәм юридик затларның, дәүләт яисә муниципаль мөлкәтнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясына һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XXII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына таянып, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштыру турында»карарларга нигезләнеп,

КАРАР БИРӘМ:

Билгеләргә:

2023 елның 20 декабреннән 2024 елның 10 гыйнварына кадәр Чирпы авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим;

1. Махсус янгынга каршы режим чорында 1-3 классны хәвефлелектәге пиротехник эшләнмәләрдән (бенгаль утларыннан, мамык кисәкләреннән тыш) файдалануны тыярга:

Сәнәгать объектлары, транспорт инфраструктурасы (автомобиль юлларыннан тыш), ягулык-энергетика комплексы (шул исәптән линия)чикләреннән 500 метр ераклыкта,

Торак-коммуналь хуҗалык, авыл хуҗалыгы объектлары, кешеләр күпләп булган объектлар, автомобиль юллары, шәхси йортлар чикләреннән 30 метр; күп фатирлы торак йортлардан 30 метр ераклыкта.

2. Чирпы авыл җирлеге гражданнарына пиротехниканы куллану өчен 3 урын билгеләргә

- Имәнкискә авылы, авылдан чыгу урынында, Полянка торак пункты ягына;

Чирпы авылы, авыл клубы янындагы спорт мәйданчыгында;

Мирәтәк авылы, авылдан чыгу урынындагы мәйданчыкта

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

4. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Имәнкискә авылы, Совет урамы, 23а;

Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Чирпы авылы, Завод урамы, 22;

Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Мирәтәк авылы, Озерная урамы, 5б.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Чирпы**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Зотин Р.Ю.**